| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ИВАНОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИВАНОВКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30 октябрь 2020 ел № 5

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Михайловка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлеге Уставы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Михайловка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 15 ноябренә 11 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлеге Михайловка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларда, күп балалы гаиләләрдән тыш, алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 500 сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме?:

I. Җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту:

- Михайловка авылы Югары урамы буенча юлларга вак таш җәю;
- Михайловка авылында (Үзәк ур., Югары ур.) юлларны кардан чистарту.

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Михайловка авылы, Центральная, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы
«Ивановка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.П.Бодряева